# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## К А Р А Р

«02» 03 2020 ел Яр Чаллы № 546

Тукай муниципаль районы мәгариф оешмаларында инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы мәгариф оешмаларында инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итү тәртибен, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтүне 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә 3 көн эчендә әлеге карарны Тукай муниципаль районы сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Н.С. Габдуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г.Авзалов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның ___ 02. ___ 546 номерлы карарына кушымта

**Тукай муниципаль районы мәгариф оешмаларында инвалидлар өчен уңайлы шартлар тәэмин итү тәртибе**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының мәгариф оешмалары җитәкчеләре законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга мәгариф оешмаларында түбәндәге шартларны тудыралар һәм тәэмин итәләр:

- объектларга киртәләрсез керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;
- хезмәт күрсәтү урынына керү өчен объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән хезмәт күрсәтүче объект хезмәткәрләре ярдәмендә;
- объектка керү урыны каршында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, объект хезмәткәрләре ярдәме белән;
- күрү функциясе тотрыклы бозылган инвалидларны озата бару һәм объект хезмәткәрләре ярдәмендә объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;
- объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында инвалидка объект хезмәткәрләре ярдәмендә хәбәр итү;
- хезмәт күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү, алар тарафыннан хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләр кылу турында мәгълүмат алу өчен инвалидларга кирәкле ярдәм күрсәтү;
-психологик-медик-педагогик комиссия бәяләмәсендәге тиешле рекомендация яки инвалидны шәхси тернәкләндерү программасы нигезендә мәгариф оешмасы тарафыннан тьютор хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итү;
- түләүсез дәреслекләр һәм уку әсбаплары, башка уку әдәбияты, шулай ук күмәк һәм шәхси кулланыштагы махсус техник чаралар бирү;
- мәгариф оешмалары хезмәткәрләре тарафыннан башка затлар белән беррәттән мәгариф өлкәсендә хезмәтләр алуга һәм объектлардан файдалануга комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда инвалидларга башка кирәкле ярдәм күрсәтү.